СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 28 » апрель 2017 ел** **№ 126**

**Арча район Советының 31.01.2011ел, № 31.3 (27.12.2013 №243.1, от 06.05.2014 №268, от 19.02.2016 №34, от 07.04.2016 №46 үзгәрешләр белән) карары белән расланган Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппараты турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Арча муниципаль районы башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфалары реестрыннан «Эшләр идарәчесе» вазыйфасын чыгаруга бәйле рәвештә, Арча район Советы карар бирде:

Арча район Советының 31.01.2011ел, №31.3 карары белән расланган Арча муниципаль районы башкарма комитеты аппараты турындагы Нигезләмәгә (27.12.2013 №243.1, от 06.05.2014 №268, от 19.02.2016 №34, от 07.04.2016 №46 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) муниципаль район башкарма комитеты аппараты структурасыннан «Башкарма комитетның эшләр идарәчесе» вазифасын һәм «Аппарат структурасы» 3.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Муниципаль район башкарма комитеты аппаратына түбәндәгеләр керә:

1. Башкарма комитет җитәкчесе ярдәмчесе.

2. Оештыру-гомуми бүлеге:

- архив эшләрен исәпкә алу һәм алып бару секторы;

-мәгълүмат-коммуникация технологияләре һәм мәгълүматны яклау секторы.

3. Инфраструктура үсеше бүлеге:

- шәһәр төзелеше һәм архитектура секторы;

- ТКХ, энергетика һәм элемтә секторы.

4. Икътисад һәм финанс бүлеге.

5. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге.

6. Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге.

7.ГХАТ бүлеге.

8. Опека һәм попечительлек секторы.

9.Әйдәп баручы белгеч.

Башкарма комитет аппараты хезмәткәрләренең структурасы һәм саны башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан раслана.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев